**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОТУМБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Яңа Тумба ав

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№22 «19» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы карары (2021 елның 18 ноябрендәге 20 номерлы, 2024 елның 18 июнендәге 12 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Гариза белән "кадастр эшчәнлеге турында" Федераль законның 35 статьясында яисә 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслашу объекты булган тиешле күчемсез мөлкәт объектына карата кадастр эшләрен яисә Комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Нурлат муниципаль районының

«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Л.Н. Осипов